# КАРАР

23 ноябрь, 2023 ел №7

«Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Зур Сәрдек торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану турында 2022 елның 17 ноябрендәге 5 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәлә буенча Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Зур Сәрдек авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Зур Сәрдек авыл җирлеге Уставы нигезендә 2023 елның 22 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Зур Сәрдек торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 17 ноябрендәге 5 номерлы Иске Йорт авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә Сез ризамы:

15 нче пунктны өстәргә:

«15. Зур Сәрдек авылы мәдәният йортына сәхнә киемнәре, спорт инвентары һәм җиһазлар әзерләү, сатып алу»

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 711 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 369 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 369 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Зур Сәрдек авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Зур Сәрдек торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 17 ноябрендәге 5 номерлы Зур Сщрдек авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә Сез ризамы:

15 нче пунктны өстәргә:

«15. Зур Сәрдек авылы мәдәният йортына сәхнә киемнәре, спорт инвентаре һәм җиһазлар әзерләү, сатып алу»

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Зур Сәрдек авыл җирлеге башлыгы: Ф.М. Фәттахов

ОГРН 1021607753232
ИНН 1623001727